**Республика Татарстан**
**Совет Старо-Имянского сельского поселения**
**Сармановского муниципального района**
423373, с. Старый Имян,
ул. М. Вахитова,36 в

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районы**
**Иске Имэн авыл жирлеге Советы**
423373, Иске Имэн авылы,
М. Вахитов урамы, 36 в йорт

**КАРАР** **КАРАР**

**01 февраль 2016 года** **№20**

## Иске Имән авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

12.06.2002 ел, № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» гы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п., Иске Имән авыл җирлеге Уставының 11,12 ст. нигезендә Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Советының 2016 елның 25 гыйнварында кабул ителгән карары №19 « референдум үткәрү инициативасы турында» нигезендә, Иске Имән авыл җирлеге Советы КАРАР итте:

1. Иске Имән авыл җирлеге территориясендә 2016 елның 20 мартына гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2016 елда Иске Имән авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешегә 200 сум күләмендә үзара салым акчасын кертүгә, I төркем инвалидларыннан тыш, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме?:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:
- Сарысаз-Тәкермән т. п. янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру 2 мең сум.
- җирлек территориясендә физик культура һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар булдыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру 12,0 мең сум;
- җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктырту, территорияне яшелләндерүне дә кертеп) 16,6 мең сум;
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге 24,0 мең сум;
- көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны җыю һәм чыгаруны оештыру-12,0 мең сум;

«ӘЙЕ» " ЮК»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән 5 көн эчендә халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге
Советырәисе Р.Ә.Исламова